РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИХАЙЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИХАЙЛОВКА ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423975 РТ, с. Михайловка. Ул. Гагарина, 24. тел. (8-85556) 3-62-32*

**КАРАР № 1**

Михайловка авылы 20. 01. 2021ел.

**Кар өю урыннары турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлеге территориясендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе таләпләре нигезендә, Михайловка авыл җирлеге Уставына һәм «Төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә» таянып, интенсив кар яву чорында юлларны, урамнарны, мәйданнарны үз вакытында чистартуны тәэмин итү, елның кышкы чорында уңай экологик хәл булдыру максатларында, Михайловка авыл җирлеге башкарма комитеты түбәндәгеләрне КАРАР БИРӘ:

1. Михайловка авылы һәм Элемтә авылы торак пунктларыннан китерелә торган карны 1079 кв.м мәйданлы буш урынны кадастр номеры 16:29:160201:74 булган җир кишәрлегендә билгеләргә.
2. Михайловка авыл җирлеге башкарма комитетына ел саен түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:
   2. 1. Карны вакытлыча салып тору һәм аңа килү юллары өчен мәйданчык әзерләү;
   2. 2. Кар эрү чоры тәмамлангач, кар вакытлыча җыела торган мәйданчык территориясен рекультивацияләүне һәм чистартуны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Михайловка авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.
5. Әлеге карар кул куелганнан бирле үз көченә керә.

Михайловка авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе Исламов Р.Х.